# Каз өмәсе.
# Ишим авылы, Хасанова Р.Н.





- Борынгыдан татар халкы
- Су буена урнашкан.
- Йорт төзегән, бакчасында
- Яшелчәләр үстергән.



- Иң беренче йорт кошын -
- Каз да карый башлаган.

- Чыгымы аз булган казның,
- Су буенда тукланган.



- Файдасы зур булган казның:
- Түшәк, мендәр ясалган…




- Иң тәмле бәлешләр дә
- Шул каз итеннән булган.





- Каурыйлардан каләм ясап,
- Хат язышулар булган…

- Өшеткәндә кул-битләрне
- Каз мае бик булышкан.
- 





- Казның эше күп инде ул:
- Бәбкәсен карауларга…
- Каурыйларын аерым йолкып,
- Мамыкларын алырга…



- “20 каз -
- атка тора”,
- Күпләп каз караганнар.
- Бер-берсенә ярдәмләшеп ,
- Казларны эш иткәннәр.



- Каз «пумиче» акрын шулай
- Гадәткә кереп калган:

- Татарның зур бәйрәменә -
- Каз



- Өлкән яшьтәге апалар
- Кызларны күзәткәннәр.
- Иң унганнарын хәтерләп,
- Киленгә сайлаганнар
.
- 




- Каз өмәсе зур вакыйга
- Булган һәрбер гаиләдә:

- Егетлэр кәләш сайлаган
- Кызлар каз йолыкканд а.



- Юк-бар сәбәп табып торып,
- Кыз янына кергәннәр.
- Күңелләрен күтәрергә
- Гармунда уйнаганнар.



- Елгага кызлар төшкәндә
- Каурыйларны чәчкәннәр.

- Кызлар казларны юганда
- Кырында үрелгәннәр.








- Казларның эшен бетереп,
- Кичен бәйрәм иткәннәр.

Сыйланганнар, жырлаганнар,

- Хәлләрен белешкәннә



- Туйга да әти-әниләр
- 2 каз пешерәләр,
- Кунаклар бүләк салалар,
- Яшьләргә теләк теләп.



- Ата каз туг(ы)рыклы була,
- Ана казның алдында.
- Ана казны алыштырмый,
- Һич тә тормыш юлында.
- 

- Башын кияугә бирәләр,
- Тормышка хуҗа булсын,
- Муены әләгә кәләшкә –



- Аяк бирелә кияүгә,
- Туры юлдан йөрсен дип.



- Канат бирелә кәләшкә,
- Сыйдырсын барысын дип.
- 

- Матур гадәтләребезне
- Саклыйк инде бүген дә.
- Бергәләшеп, тату гына,
- Яшик әле без,
- көн дә!
-
- Хасанова Р.Н., “Мирас” төркеме җитәкчесе, Ишим авылы.
-

# Гореф-гадәтләрне саклаучы, туплаучы «Ирень таңнары» ансамбле.



# Фотолар кубесе интернет челтәрләреннән алынган (локдаун). 2021 ел.



Хасанова Р. Н., “Мирас” төркеме җитәкчесе, Ишим авылы.